ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

**18.12.2017** | **161**

пос. Октябрьский

Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәрен әзерләү һәм уздыру чорында социаль әһәмиятле объектларның, кешеләр күпләп була торган урыннарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм гражданнарның иҗтимагый иминлеген тәэмин итү буенча өстәмә чаралар турында.

Яңа ел һәм Раштуа бәйрәмнәрен үткәрү чорында гражданнарның һәм юридик затларның тормышын, сәламәтлеген, мөлкәтен, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне янгыннан саклау максатыннан

КАРАР БИРӘМ:

1. Октябрьский авыл җирлеге халкы тарафыннан пиротехника әйберләрен махсус куллану урыннарын билгеләргә:
   - футбол кыры (Октябрьский бистәсе, Октябрьский авылы Мәдәният йорты бинасыннан илле метр ераклыкта)

   -Яңа-Болгар авыл клубының үзәк ишегеннән көньяк-көнбатышка таба илле метр ераклыкта (Яңа а-Болгар авылы, Яңа Болгар авыл клубы бинасыннан илле метр ераклыкта)

   - мәдәният һәм ял паркы (Матюшино авылы Матюшино авыл клубы бинасыннан илле метр ераклыкта)

   - Ключищи авыл клубы бинасыннан илле метр ераклыкта алма бакчасы (Ключищи авылы)

2. Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү, Яңа ел һәм раштуа бәйрәмнәрен үткәргәндә социаль әһәмияткә ия объектларны саклауны көчәйтү буенча җаваплы зат итеп Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Азизов Шамил Рәмис улын билгеләргә.
3. Әлеге карарны Октябрьский авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:
Югары Ослан муниципаль районы буенча
РФ Гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының
ТР буенча Баш идарәсе ОНД начальнигы
Янгын күзәтчелеге буенча баш дәүләт инспекторы
эчке хезмәт подполковнигы А.Д. Садыйков